**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы №31 «28» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендэге 97 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (12.11.2015 №14, 13.12.2016 №46, 23.04.2019 №129, 03.02.2020 №160, 24.02.2021 №2, 23.09.2021 №15, 18.04.2023№15, 20.10.2023 №31, 22.01.2024 №1 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 2024 елның 08 августындагы 232-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендэге 97 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карарына (12.11.2015 №14, 13.12.2016 №46, 23.04.2019 №129, 03.02.2020 №160, 24.02.2021 №2, 23.09.2021 №15, 18.04.2023 № 15, 20.10.2023№31, 22.01.2024 №1 карарлар редакциясендә)
түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Нигезләмәдә депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының статусы билгеләнми, чөнки күрсәтелгән затлар муниципаль хезмәткәр булып саналмый.».

1.2. 4.1 бүлекнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле

үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

1.3. 4.2 бүлекнең 1 өлешендә:

а) 1 пунктның " в "пунктчасында", муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга.;

б) 2 пунктта:

- "а " пунктчасында", муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында " сүзләрен төшереп калдырырга.;

- «б» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында " сүзләрен төшереп калдырырга.;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җирле үзидарә органында ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән яисә федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры аңа буйсынган өченче зат эшләре буенча вәкил булырга;»;

г) 5 пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен «анда» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «, сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 9 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә һәм аларның җитәкчеләренә» сүзләрен «һәм аның җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә” түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Г.Солтанова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АЗНАКАЕВСКИЙ РАЙОН ДЕРЕВНЯ БИРЮЧЕВКА
ИНН 1643003049
КПП 164301001
ОГРН 1021601571672
«БИРЮЧЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН